Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре №5

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 26 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 26 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 26 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресы буенча урнашкан Янил авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокләы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 720 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Янил авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета, экспертиза документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

2) Татарстан урамында, Яңа урамда, Яр буе урамында юлларга вак таш җәю (ком һәм вак таш сатып алу, ташу, салу), проект-смета докуменларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү;

3) Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләрен сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

4) Янил авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Янил авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов